Приложение № 12
к приказу Управления образования
№ от « » 2019г.

**Нигезләмә**
**Шәһәр буенча үткәреләчәк “Казан сандугачы” җыр бәйгесе тәртибе**
**2020 г.**

Казан шәһәре Мәгариф идарәсе шәһәр администрациясенең Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятен үстерү фонды һәм А.Алиш исемедәге балалар иҗат Сарае 1996 нчы елдан башлап, татар халык җырларын, татар эстрада җырларын иң оста башкаручылар арасында “Казан сандугачы” җыр бәйгесе үткәрә.

**Оештыру әгъзалары:**

Казан шәһәре Мәгариф идарәсе һәм А.Алиш исемендәге балалар иҗат Сарае.

**Бәйгенең максатлары һәм бурычлары:**

- Татар эстрада җырларын иң оста башкаручыларны сайлап алу;
- Балаларда татар халык сәнгатенә, мәдәниятенә, көй-моңнарына мәхәббәт уяту;
- Балалар репертуарларында фольклор-этнографик композицияләре булдыру;
- Сәләтле балалар табу;
- Яшь талантларны үстерү.

**Үткәрү тәртибе:**

Бәйге II этапта уздырыла:

I – районнарда сайлап алу туры (1 декабрьдән 20 нче гыйнварга кадәр).

II – шәһәр күләмендә сайлап алу; - гыйнвар 2020 г.

**Җыр бәйгесе өч номинациядә үткәрелә:**

- татар эстрада җыры;
- татар халык җыры;
- фольклор композициясе;

<u>Катнашучылар 1 номер башкара.</u>

Бәйгедә 6 яшьтән 18 яшькә кадәр теләкләре булган балалар катнаша ала.

Алар, яшь аермасына карап, 4 төркемгә бүленә:

6-8 яшькә кадәр; 9-12 яшькә кадәр; 13-15 яшькә кадәр; 16-18 яшькә кадәр.

**Катнашучылар:**

Бәйгедә урта мәктәп һәм балалар иҗат үзәкләрендә шөгыльләнүче укучылар катнаша ала. Тәкъдимнәр А.Алиш исемендәге балалар иҗат Сараенда кабул ителә.

**Бәйгенең таләпләре:**

- чиста, әйбәт дикция белән башкару;
- артистлык осталыгы (сәхнәдә үзеңне иркен, культуралы тота белү, йөз мимикасы, тән хәрәкәте, композициянең эчтәлегенә туры килү);
- микрофонны куллана белү;
- сәхнә киеме культурасы.

**Бәйгегә нәтиҗә ясау:**

Йомгаклау гыйнвар аенда, шунда ук бүләкләү.

**Оештыру һәм җюри әгъзалары**:

Жюрида мәдәният һәм сәнгать университеты укытучылары һәм җөмһүриятебезнең танылган сәнгать осталары булачак.

Призлы урыннар алган укучылар номинация буенча бүләкләнә.

Тәкъдимнәр район Мәгариф бүлегеннән  гыйнварга кадәр А.Алиш исемендәге балалар иҗат Сараенда кабул ителә.

(Шәһәр этабы буенча районнарда I, II, III урыннар алган балалар катнашалар).

**Белешмәләр өчен телефоннар:** 238-48-19, 292-37-04,

**Электронный адрес** alishadmm19@mail.ru .